ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.110, с. Макулово,
422582

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы,
422592

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

с. Русское Макулово

23.10.2025 03-01/39

## Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү урыннарын билгеләү турында

«Хайваннар белән җаваплы эш итү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, «Йорт хайваннарын тотуга өстәмә таләпләр раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 11 августындагы 971 номерлы карары нигезендә, гражданнарның, хайваннарның иминлеген, физик һәм юридик затларның мөлкәтен саклап калуны тәэмин итә торган йорт хайваннарын йөртү өчен шартлар тудыру максатларында, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Уставы белән, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Йорт хайваннарын йөртү өчен рөхсәт ителгән түбәндәге урыннарны билгеләргә:

1.1. файдаланудагы яисә гражданнар милкендәге җир кишәрлекләре;

1.2. халык күпләп җыелмаган авыл җирлеге территориясендә (тыкрыклар, бушлыклар, торак сектор һәм җәмәгать урыннары артындагы урыннар).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Макыл авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.В. Гусева